ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.04.2024 Мөслим авылы № 179

**Җир кишәрлегендә урнашкан биналар, корылмалар милеккә яисә муниципаль милектәге җир кишәрлеген арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, “Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен һәм раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 02 декабрендәге 880 номерлы карарына таянып, “Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставының 63 маддәсе белән, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Расларга:

1.1. Җир кишәрлегендә урнашкан биналар, корылмалар милеккә яисә муниципаль милектәге җир кишәрлеген арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (1 нче кушымта).

2. Мөслим муниципаль районының мөлкәти һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы биш эш көне эчендә югарыда күрсәтелгән административ регламентны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә. http://muslumovo.tatarstan.ru.http://muslumovo.tatarstan.ru

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мөслим муниципаль районы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре Палатасы рәисе Р. Ф. Хантимеровка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Ф.Салихҗанов**

Татарстан Республикасы Мөслим
муниципаль районы Башкарма
комитетының 2024 елның «16»
апрелендәге 179 номерлы карарына
кушымта

**Муниципаль милектә булган, дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен әлеге җир кишәрлекләрендә урнашкан биналарның, корылмаларның хуҗаларына милеккә яисә арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – Регламент) муниципаль милектә булган, дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен әлеге җир кишәрлекләрендә урнашкан биналарның, корылмаларның хуҗаларына милеккә яисә арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгеле (алга таба – муниципаль хезмәт).

1.2. Муниципаль хезмәттән файдаланучылар – физик һәм юридик затлар (алга таба – гариза бирүче).

1.3. Муниципаль хезмәт Мөслим муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан күрсәтелә (алга таба – Палата).

1.3.1. Палатаның урнашкан урыны: Мөслим ав.,Пушкин ур., 91 й.

Эш графигы:

дүшәмбе – җомга, сәгать 8.00 дән 17.00 гә кадәр;

төшке аш – 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр.

шимбә, якшәмбе: ял көннәре.

Белешмә өчен телефон: 8 (85556) 2-54-50.

Бинасына керү шәхесне раслый торган документлар нигезендә башкарыла.

1.3.2. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге (алга таба – «Интернет» челтәре) муниципаль район рәсми сайтының адресы: (http://muslumovo.tatarstan.ru).

1.3.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү, шулай ук Палатаның урнашкан урыны һәм эш графигы турында мәгълүмат түбәндәгеләрдән алынырга мөмкин:»;

1) муниципаль хезмәт турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган, гариза бирүчеләр белән эшләү өчен идарә биналарында урнаштырылган мәгълүмат стендлары ярдәмендә.

Татарстан Республикасының дәүләт телләрендәге мәгълүмат әлеге Регламентның 1.1, 1.3.1, 2.3, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында булган муниципаль хезмәт турындагы белешмәләрне үз эченә ала;

2) «Интернет» челтәре аша муниципаль районның рәсми сайтында (http://muslumovo.tatarstan.ru);

3) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында http://uslugi. tatar.ru/;http://www.aksubayevo.tatar.ru

4) Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http:/ www.gosuslugi.ru/);http://www.gosuslugi.ru/

5) Палатада:

телдән мөрәҗәгать иткәндә – шәхсән яки телефон буенча;

язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә – кәгазь чыганакта почта аша яки электрон формада электрон почта аша алырга мөмкин.

1.3.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат муниципаль районның рәсми сайтында һәм Палатаның гариза бирүчеләр белән эшләү өчен каралган бүлмәләрендәге мәгълүмат стендларында урнаштырыла.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге документлар нигезендә гамәлгә ашырыла:

Россия Федерациясе Граждан кодексы 30.11.1994 № 51-ФЗ (Россия Федерациясе законнары җыелышы, 05.12.1994, №32, 3301 статья);

Россия Федерациясенең Җир кодексы (алга таба – РФ ҖК) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 29.10.2001, №44, 4147 б.);

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль закон (Россия Федерациясе Законнар җыелмасы, 06.10.2003, №40, 3822 статья);

2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»гы Федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 02.08.2010, №31, 4179 ст.);

Россия Икътисадый үсеш министрлыгының «Гариза бирүченең сату үткәрмичә җир кишәрлеген алу хокукын раслый торган документлар исемлеген раслау турында» 2015 елның 12 гыйнварындагы 1 номерлы боерыгы (алга таба - №1 боерык) (хокукый мәгълүмат рәсми интернет-порталы http://www.pravo.gov.ru 28.02.2015);

Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 2014 елның 27 ноябрендәге 762-нче номерлы «Җир кишәрлеген яки җир кишәрлекләрен территориянең кадастр планында урнаштыру схемасын әзерләүгә һәм җир кишәрлеген яки җир кишәрлекләрен территориянең кадастр планында урнаштыру схемасын электрон документ формада әзерләгәндә, җир кишәрлеге яки җир кишәрлекләрен территориянең кадастр планында урнаштыру схемасы формасы кәгазь документ формасында әзерләнгәндә, җир кишәрлеген яки җир кишәрлекләрен территориянең кадастр планында урнаштыру схемасы форматына караган таләпләрне раслау турында»гы боерыгы (хокукый мәгълүматның рәсми интернет порталы (www.pravo.gov.ru), 18.02.2015);

2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы Татарстан Республикасы законы (алга таба – 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы) («Республика Татарстан», 03.08.2004, №155-156);

Мөслим муниципаль район Советының 2012 елның 30 маендагы 84 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Уставы (алга таба – Устав);

Мөслим муниципаль районы Советы карары белән расланган 2019 елның 24 маендагы 147 номерлы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты турында нигезләмә (алга таба – БК турында Нигезләмә);

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы турында Советның 2006 елның 11 февралендәге 33 номерлы карары белән расланган нигезләмә (алга таба – палата турында Нигезләмә);

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыны – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22 декабрендәге 1376 нчы номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында»гы карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль районы авыл җирлегендә яки шәһәр җирлегендә (шәһәр округында) оештырылган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең территориаль яктан аерымланган структур бүлекчәсе (офис);

техник хата – муниципаль хезмәт күрсәтә торган орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенә) кертелгән мәгълүматларның алар нигезендә мәгълүматлар кертелгән документлардагы мәгълүматларга туры килмәвенә китергән хата (ялгыш язу, басма хата, грамматик яки арифметик хата яки шуңа охшаш хата).

Әлеге Регламентта муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) дигәндә муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы запрос аңлашыла (27.07.2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 2 нче пункт). Гариза стандарт бланкта тутырыла (1 номерлы кушымта).

## 2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына куелган таләпнең атамасы | Стандартка куелган таләпләрнең эчтәлеге | Хезмәтне яки таләпне билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Муниципаль хезмәтнең атамасы | Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген, җир кишәрлегендә урнашкан биналар, корылмаларның милекчеләренә милеккә яки арендага бирү | ст. 39.20 ЗК РФ |
| 2.2. Җирле үзидарәнең муниципаль хезмәтне турыдан-туры күрсәтүче башкарма-боеру органы исеме | Палата | Палата турында нигезләмә |
| 2.3.Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең тасвирламасы | Күчемсез мөлкәт объекты (ами) биләгән муниципаль милектәге җир кишәрлеген сату-алу яисә арендалау шартнамәсе, җир кишәрлеген тапшыру акты;<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу турында карар | |
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, | Гариза алынганнан соң 12 көн эчендә җир кишәрлеген милеккә яки арендага бирү турында Карар кабул итү.[1]<br>Акча күчерү турында белешмәләр кергән көннән алып, бер көн эчендә имзаланган шартнамәне бирү.<br>Гариза бирүче тарафыннан акча күчерүгә тотылган | |

[1]Муниципаль хезмәт күрсәтүнең вакыты административ процедураларны башкару өчен кирәкле иң кыска вакыт аралыкларын бергә кушудан чыгып билгеләнә. Административ процедураларның вакыты эш көннәрендә исәпләнә.

| | | |
|---|---|---|
| муниципаль хезмәт күрсәтү срогы, Россия Федерациясе законнары белән каралган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору срогы | вакыт муниципаль хезмәт күрсәтү вакытына керми.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган | |
| 2.5. Закон актлары һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә муниципаль хезмәт, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү буенча кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләрне күрсәтү өчен зарур булган, гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, гариза бирүче тарафыннан аларны алу, шул исәптән электрон формада алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе. | 1) Гариза.<br>2) Документлар (2 нче Кушымта)<br>Гариза бирүче муниципаль хезмәттән файдалану өчен гариза бланкын Башкарма комитетка шәхсән мөрәҗәгать итеп алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Башкарма комитетның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм аңа беркетелгән документлар гариза бирүче тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсен кулланып тапшырыла (җибәрелә) ала:<br>шәхсән (гариза бирүче исеменнән ышанычнамә нигезендә эш итүче зат тарафыннан);<br>почта аша.<br>Гариза бирүче гариза һәм документларны шулай ук көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре аша, шул исәптән Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәре һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы аша да бирергә (җибәргә) мөмкин. | 475 нче номерлы боерык |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле, дәүләт | Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында түбәндәгеләр алына:<br>1) Аерым затның үзенә караган күчемсез милек объектларына хокуклары турында күчемсез | 475 нче номерлы боерык |

| | | |
|---|---|---|
| органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган һәм гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларның тулы исемлеге, шулай ук гариза бирүченең аларны, шул исәптән электрон формадагыларын да, алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар үз карамагында булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яки оешма | милекнең Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;<br>2) күчемсез милек объектының төп характеристикалары һәм аңа теркәлгән хокуклар турында күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;<br>3) Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;<br>Гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән.<br>Гариза бирүчедән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы югарыда санап үтелгән документларны таләп итү тыела.<br>Гариза бирүченең югарыда күрсәтелгән мәгълүматларны үз эченә алган документларны тапшырмавы гариза бирүчегә хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый | |
| 2.7. Норматив хокукый актларда каралган очракларда килештерү хезмәт күрсәтү өчен таләп ителгән һәм муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт хакимияте органнары (җирле үзидарә органнары) һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | Муниципаль хезмәтне килештерү таләп ителми | |
| 2.8. Муниципаль хезмәт | 1) Документларның тиешле булмаган зат | |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | тарафыннан тапшырылуы;<br>2. Тапшырылган документларның әлеге регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәве.<br>3) Гаризада һәм гаризага беркетелә торган документларда килештерелмәгән төзәтүләр, аларның эчтәлеген бертөрле генә аңларга мөмкинлек бирми торган җитди кимчелекләр бар;<br>4) Документларны тиешле булмаган органга тапшыру | |
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору яки муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Хезмәт күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>Баш тарту өчен нигезләр:<br>1) җир турында законнар нигезендә җир кишәрлеген сатулар үткәрмичә сатып алуга хокукы булмаган затның җир кишәрлеген бирү хакындагы гариза белән мөрәҗәгать итүе;<br>2) җир кишәрлеген бирү турындагы гариза белән әлеге хокукларга ия булган зат мөрәҗәгать иткән яки җир кишәрлеген бирү турындагы гариза РФ Җир кодексының 39.10 статьясындагы 2 пунктының 10 пунктчасы нигезендә бирелгән очраклардан тыш, җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану, түләүсез файдалану, гомерлек мирас итеп биләү яисә арендалау хокукында бирелгән булу;consultantplus://offline/ref=B35BAAD54DB3A73535A0989919E3856F3E6A878420AAB03876044D5567BE6D21450402DF89YA75G<br>3) әгәр җир кишәрлеге гомуми файдаланудагы | 39.16 ЗК РФ |

| | | |
|---|---|---|
| | милек булып, әлеге коммерциячел булмаган оешма әгъзасы яисә әлеге коммерциячел булмаган оешма гариза белән мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш, җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге яшелчәчелек, бакчачылык, дача хуҗалыгы алып бару яисә шәхси торак төзелеше максатыннан территорияне комплекслы үзләштерү өчен гражданнар тарафыннан булдырылган коммерциячел булмаган оешмага бирелгән;<br>4) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегендә гражданнарга һәм юридик затларга караган бина, корылма, төзелеп бетмәгән төзелеш объекты урнашкан, корылма (шул исәптән төзелеше тәмамланмаган корылма) сервитут шартларында җир кишәрлегендә урнашкан яисә җир кишәрлегендә РФ ҖК 39.36 маддәсенең 3 пунктында каралган объект урнаштырылган, һәм бу җир участогыннан рөхсәт ителгән файдалану нигезендә файдалануга комачауламый, яки җир кишәрлеге бирү турында гариза белән әлеге биналарның, корылмаларның, алардагы бүлмәләрнең, әлеге объектның милекчесе мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш;<br>5) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегендә дәүләт яки муниципаль милектә булган бина, корылма, төзелеп бетмәгән төзелеш объекты урнашкан, корылма (шул исәптән төзелеше тәмамланмаган корылма) сервитут шартларында җир кишәрлегендә урнашкан яисә җир кишәрлеге бирү турында гариза белән әлеге | |

| | | |
|---|---|---|
| | биналарның, корылмаларның, алардагы биналарның, әлеге төзелеп бетмәгән төзелеш объектының хокук иясе мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш;<br>6) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге әйләнештән алынган булу яки аның әйләнештә булуы чикләнү һәм җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән хокукта аны бирү рөхсәт ителмәү;<br>7) җир кишәрлеген резервлау максатыннан бирү очрагыннан тыш, гариза бирүче җир кишәрлеген милеккә, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга бирү турындагы гариза яки җир кишәрлеген аны резервлау турындагы карарның гамәлдә булу вакытыннан арткан вакытка арендага, түләүсез файдалануга бирү турындагы гариза белән мөрәҗәгать иткән очракта, җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге дәүләт ихтыяҗлары яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен резервланган булу;<br>8) җир кишәрлеге бирү турындагы гариза белән әлеге җир кишәрлегендә урнашкан бина, корылма, алардагы бүлмәләр, төзелеш эшләре тәмамланмаган объект милекчесе яки мондый җир кишәрлеге милекчесе мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш, җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге төзелеш территориясен үстерү турында башка зат белән шартнамә төзелгән территория чикләрендә урнашкан булу;<br>9) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге төзелешле территорияне үстерү турында башка зат белән шартнамә төзелгән | |

| | | |
|---|---|---|
| | территория чикләрендә урнашкан, яисә җир кишәрлеге территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамә төзелгән җир кишәрлегеннән төзелгән, моңа федераль әһәмияттәге объектларны, региональ әһәмияттәге объектларны яисә җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру өчен шундый җир кишәрлеге бирү турындагы гариза белән күрсәтелгән объектлар төзелешенә вәкаләтле зат мөрәҗәгать иткән булса;<br>10) җир кишәрлеген арендага бирү турындагы гариза белән әлеге затның күрсәтелгән объектларны төзү буенча йөкләмәсен күздә тоткан территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамә яисә төзелгән территорияне үстерү турында шартнамә корылган зат мөрәҗәгать иткән очраклардан кала, җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамә яисә төзелгән территорияне үстерү турында шартнамә корылган җир кишәрлегеннән булдырылган һәм территорияне планлаштыруның расланган документлары нигезендә федераль әһәмияттәге объектларны, региональ әһәмияттәге объектларны яисә җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру өчен каралган;<br>11) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге аукцион предметы булу, аны үткәрү хакында белдерү кәгазе РФ Җир кодексының 39.11 статьясындагы 19 пункты нигезендә урнаштырыла;<br>12) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада | |

| | | |
|---|---|---|
| | күрсәтелгән җир кишәрлегенә карата аны сату буенча аукцион яки аны арендалау шартнамәсен төзү хокукына аукцион үткәрү турында РФ Җир кодексының 39.11 статьясындагы 4 пунктның 6 пунктчасы белән каралган гариза алыну. Әлеге очракта мондый җир кишәрлегенең РФ Җир кодексының 39.11 статьясындагы 4 пунктның 4 пунктчасы нигезендә ясалуы һәм вәкаләтле орган тарафыннан РФ Җир кодексының 39.11 статьясындагы 8 пунктында каралган нигезләр буенча әлеге аукционны үткәрүне кире кагу турында карар кабул ителмәгән булу шарт;<br>13) аны бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенә карата Россия Федерациясе Җир кодексының 39.18 статьясындагы 1 пунктының 1 пунктчасы нигезендә җир кишәрлеген шәхси торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык эшен алып бару яисә крестьян (фермер) хуҗалыгы тарафыннан аның эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен бирү турында хәбәрләмәнең басылып чыгуы һәм урнаштырылуы;<br>14) территорияне планлаштыруның расланган проектына ярашлы рәвештә линия объектын урнаштыру очракларыннан тыш, җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән әлеге җир кишәрлегеннән файдалану максатына туры килми;<br>15) Россия Федерациясе Җир кодексының 39.10 статьясындагы 2 пунктның 10 пунктчасы нигезендә җир кишәрлеге бирү турында гариза бирелгән очракта, сорала торган җир кишәрлегенең оборона | |

| | | |
|---|---|---|
| | һәм иминлек ихтыяҗлары өчен бирелгән һәм әлеге ихтыяҗлар өчен вакытлыча файдаланылмый торган җир кишәрлекләренең Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә расланган исемлегенә кертелмәве;<br>16) яшелчәчелек, бакчачылык алып бару өчен граждханнар төзегән коммерцияле булмаган оешманың җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенең мәйданы федераль закон нигезендә билгеләнгән чик күләмнән артып китә;<br>17) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге территориаль планлаштыруның расланган документлары һәм (яки) территорияне планлаштыру документлары нигезендә федераль әһәмияткә ия объектларны, төбәк дәрәҗәсендәге әһәмияткә ия объектларны яисә җирле әһәмияткә ия объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән булу һәм җир кишәрлеген бирү турындагы гариза белән әлеге объектларны төзүгә вәкаләте булмаган зат мөрәҗәгать итү;<br>18) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге Россия Федерациясе дәүләт программасы, Россия Федерациясе субъекты дәүләт программасы нигезендә бина, корылма урнаштыру өчен билгеләнгән булу һәм җир кишәрлеген бирү турындагы гариза белән әлеге бинаны, корылманы төзүгә вәкаләте булмаган зат мөрәҗәгать итү;<br>19) җир кишәрлеген белдерелгән хокук төрендә бирү рөхсәт ителмәү; | |

| | | |
|---|---|---|
| | 20) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенә карата рөхсәт ителгән файдалану төре билгеләнмәү;<br>21) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге билгеле бер җирләр категориясенә кертелмәү;<br>22) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенә карата аны бирүне алдан килештерү турында гамәлдә булу вакыты чыкмаган карар кабул ителү һәм җир кишәрлеген бирү турындагы гариза белән әлеге карарда күрсәтелмәгән башка зат мөрәҗәгать итү;<br>23) җир кишәрлегендә урнашкан күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тануга бәйле рәвештә дәүләт ихтыяҗлары яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен алынган җир кишәрлекләреннән тыш, җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге дәүләт ихтыяҗлары яки муниципаль ихтыяҗлар өчен алынган булу һәм җир кишәрлеген бирүнең гаризада күрсәтелгән максаты мондый җир кишәрлегенең алыну максатларына туры килмәү;<br>24) җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге чикләре «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында»гы федераль закон нигезендә аныкланырга тиешлеге;<br>25) аны бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенең мәйданы җир кишәрлегенең урнашу схемасында, территорияне чикләү проектында яки мондый җир кишәрлеге барлыкка | |

| | | |
|---|---|---|
| | килгән урман кишәрлекләренең урнашуы, чикләре, мәйданы һәм башка сан һәм сыйфат характеристикалары турындагы проект документациясендә күрсәтелгән мәйданнан ун проценттан артыграк | |
| 2.10. Муниципаль хезмәт күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка төрле түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Муниципаль хезмәт бушлай күрсәтелә | |
| 2.11. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү өчен түләү күләмен исәпләү методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп, мондый түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза биргәндә һәм мондый хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты | Муниципаль хезмәттән файдалану турында гариза бирү вакыты, чират булган очракта, 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш | |
| 2.13. Гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы мөрәҗәгатен теркәү, шул исәптән электрон формада теркәү | Гариза кергән вакыттан алып бер көн эчендә.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон формада алынган гариза ялдан (бәйрәмнән) соң килә торган эш көнендә теркәлә | |

| | | |
|---|---|---|
| вакыты | | |
| 2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, гариза бирүчеләрнең көтү һәм аларны кабул итү урынына, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә инвалидларның күрсәтелгән объектлардан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итүгә, әлеге хезмәтләрне күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиалы мәгълүматны урнаштыруга һәм рәсмиләштерүгә карата таләпләр | Муниципаль хезмәт янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы булган, документлар тутыру өчен кирәкле җиһаз, мәгълүмат стендлары урнаштырылган бина һәм бүлмәләрдә күрсәтелә.<br>Инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү (бүлмәләргә уңайлы керү-чыгу һәм аның эчендә йөрү) мөмкинлеге тәэмин ителә.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиалы мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла | |
| 2.15. Муниципаль хезмәттән һәркем файдалана алу һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтү барышында вазифаи затлар белән аралашу саны, аларның дәвамлылыгы, муниципаль хезмәтне дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, | Муниципаль хезмәттән һәркем файдалана алу мөмкинлеге күрсәткечләре:<br>күпфункцияле үзәк бинасының җәмәгать транспорты йөри торган урынга якын урнашуы;<br>белгечләрнең, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итела торган бүлмәләрнең җитәрлек санда булуы;<br>«Интернет» челтәрендә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында районның мәгълүмати стендларында, мәгълүмати ресурсларында муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы | |

| | | |
|---|---|---|
| дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыннарында алу мөмкинлеге, муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турында, шул исәптән мәгълүмати-коммуникация технологияләреннән файдаланып мәгълүмат алу мөмкинлеге | мәгълүмат булу;<br>инвалидларга хезмәтләрдән башкалар белән тигез дәрәҗәдә файдаланырга комачаулый торган каршылыкларны узуда ярдәм итү.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфаты түбәндәгеләрнең булмавы белән билгеләнә:<br>гариза бирүчеләрдән документлар кабул иткәндә һәм аларга документларны тапшырганда чират булмау;<br>муниципаль хезмәт күрсәтү срокларын бозу;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр булмау;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә карата тупас, игътибарсыз мөнәсәбәтенә карата шикаятьләр булмау.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза биргәндә һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда, муниципаль хезмәт күрсәтүче вазифаи затның һәм гариза бирүченең бер тапкыр аралашуы күздә тотыла. Аралашу дәвамлылыгы регламент белән билгеләнә.<br>Муниципаль хезмәт дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыннары аша күрсәтелгәндә, консультация бирүне, документлар кабул итүне һәм тапшыруны күпфункцияле үзәк белгече башкара.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турында мәгълүматны мөрәҗәгать итүче муниципаль район | |

| | | |
|---|---|---|
| | сайтында алырга мөмкин (http://muslumovo.tatarstan.ru);<br>Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү (функцияләр) порталында (http://www.gosuslugi.ru);http://uslugi.tatarstan.ru<br>күпфункцияле үзәктә | |
| 2.16. Муниципаль хезмәтне электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | Муниципаль хезмәттән электрон формада файдалану тәртибе турындагы консультацияне интернет-кабул итү сәхифәсеннән яки Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан алырга мөмкин.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гаризаны электрон формада бирү закон белән каралган очракта, гариза Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://uslugi. tatar.ru/) яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталы (http://www.gosuslugi.ru/) аша бирелә. http://www.aksubayevo.tatar.ruhttp://www.gosuslugi.ru/ | |

## 3.Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм аларны башкару вакыты, аларны башкару тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон формада башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыннарында башкару үзенчәлекләре;

3.1. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә гамәлләр эзлеклелеген тасвирлау.

3.1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:
1) гариза бирүчегә консультация бирү;
2) гаризаны кабул итү һәм карап тикшерү;
3) ведомствоара мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм аларны муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү;
4) җир кишәрлеген милеккә яки арендага бирү турында карар кабул итү;
5) шартнамә төзү һәм гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү.

3.2. Гариза бирүчегә консультация бирү.

3.2.1. Гариза бирүче муниципаль хезмәттән файдалану тәртибе турында консультацияләр алу өчен палатага шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Палата белгече мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән составы, тапшырылган документлар формасы һәм муниципаль хезмәт алу өчен башка мәсьәләләр буенча консультацияләр бирә һәм кирәк булганда гариза бланкын тутыруда ярдәм күрсәтә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы буенча һәм рөхсәт алуның башка мәсьәләләре буенча консультацияләр.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче үзе, ышанычлы зат яки күп функцияле үзәк аша муниципаль хезмәт күрсәтү турында язма гаризаны һәм әлеге регламентның 2.5 пункты нигезендә документларны Палатага тапшыра.

Муниципаль хезмәтне электрон формада күрсәтү турындагы гариза Палатага электрон почта яки интернет кабул итү бүлеге аша юллана. Электрон формада кабул ителгән гаризаны теркәү билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

3.3.2.Гаризалар кабул итүне алып баручы палата белгече:

гариза бирүченең шәхесен билгели;

гариза бирүченең вәкаләтләрен тикшерә (ышанычнамә буенча эш иткән очракта);

- әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган документларның булу-булмавын тикшерә;

тапшырылган документларның билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәвен (документларның күчермәләрен тиешенчә ясау, документларда бетерелгән урыннар, өстәп язулар, сызылган сүзләр һәм башка килешенмәгән төзәтүләр булмау) тикшерә;

Җитешсезлекләр булмаган очракта Палата белгече түбәндәгеләрне башкара:

гаризаны кабул итә һәм аны махсус журналда терки;

гариза бирүчегә, документларны кабул итү көне, бирелгән керү номеры, муниципаль хезмәтне башкару көне һәм вакыты турында тамга куеп, тапшырылган документлар исемлегенең күчермәсен бирә;

карап тикшерү өчен гаризаны Палата җитәкчесенә җибәрә.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез булган очракта документларны кабул итүче Палата белгече, мөрәҗәгать итүчегә гаризаны теркәү өчен каршылыклар булуы турында хәбәр итә һәм документлар кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген язмача аңлату белән документларны кире кайтара.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар түбәндәге вакыт эчендә башкарыла:

гаризаны һәм документларны 15 минут эчендә кабул итү;

гариза кергән вакыттан аны бер көн эчендә теркәү.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, Палата башлыгына карап тикшерүгә җибәрелгән гариза, яки гариза бирүчегә кире кайтарылган документлар.

3.3.3. Палата җитәкчесе гаризаны карый, башкаручыны билгели һәм Палата белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза теркәлгәннән соң бер көн эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: башкаручыга җибәрелгән гариза.

3.4. Ведомствоара запрослар ясау һәм аларны муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү.

3.4.1. Палата белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша түбәндәгеләрне бирү турында электрон формада запрос җибәрә:

1) Аерым затның үзенә караган күчемсез милек объектларына хокуклары турында күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

2) күчемсез милек объектының төп характеристикалары һәм аңа теркәлгән хокуклар турында күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

3) Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза теркәлгәннән соң бер көн эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: хакимият органнарына җибәрелгән запрослар.

3.4.2. Ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша килгән мөрәҗәгатьләр нигезендә мәгълүмат белән тәэмин итә торган оешма белгечләре соратылган документларны (мәгълүматны) бирәләр яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның һәм (яисә) мәгълүматның булмавы турында хәбәрнамә (алга таба – кире кагу турында хәбәрнамә) юллыйлар.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар түбәндәге вакыт эчендә гамәлгә ашырыла:

Росреестр белгечләре тарафыннан җибәрелә торган документлар (белешмәләр) буенча, өч эш көненнән артык түгел;

башка тәэмин итүчеләр буенча – әгәр ведомствоара мөрәҗәгатькә җавап әзерләүнең һәм юллауның башка вакыты федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актлары һәм федераль законнар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән билгеләнмәгән булса, ведомствоара мөрәҗәгать документ һәм мәгълүмат бирә торган органга яисә оешмага кергән көннән соң биш көн эчендә.

Процедуралар нәтиҗәсе: Палатага юлланган документлар (белешмәләр) яисә баш тарту турында хәбәрнамә»;

3.5 Җир кишәрлеген милеккә яки арендага бирү турында карар кабул итү

3.5.1. Палата белгече кергән мәгълүматлар нигезендә түбәндәгеләрне башкара:

җир кишәрлеген милеккә яки арендага бирү буенча документлар яки, баш тартуның сәбәпләрен күрсәтеп, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат проекты әзерли (алга таба — баш тарту турында хат);

җир кишәрлеген милеккә яки арендага бирү буенча документлар яки баш тарту турында хат проектын рәсмиләштерә

әзерләнгән документ проектын килештерү процедураларын билгеләнгән тәртиптә башкара;

документларны яки баш тарту турында хат проектын Палата җитәкчесенә (аңа вәкаләтле затка) кул куярга җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар запросларга җаваплар алынган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Палата җитәкчесенә (ул вәкаләт биргән затка) имза куюга җибәрелгән проектлар.

3.5.2. Палата җитәкчесе (аңа вәкаләтле зат) карар проектын раслый, карарга кул куя һәм аны мөһере белән раслый яки баш тарту турында хатны раслый һәм имзалый. Имзаланган документлар Палата белгеченә җибәрелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура проект раслауга кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзаланган дубликат яки баш тарту турында хат.

3.5.3. Палата белгече:

документ яки баш тарту турында хат терки.

гаризада күрсәтелгән элемтә ысулыннан файдаланып, гариза бирүчегә (аның вәкиленә) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр итә,

рәсмиләштерелгән рөхсәтне яки муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу турында хатны бирү көнен һәм вакытын хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар документларга кул куелган көнне Палата җитәкчесе тарафыннан башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә (аның вәкиленә) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр итү.

3.5.4. Палата белгече гариза бирүчегә (аның вәкиленә), имза куйдырып, рәсмиләштерелгән күрсәтмә яки баш тарту турында хат бирә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар түбәндәге вакыт эчендә башкарыла:

документны бирү - гариза бирүче килгән көнне чират тәртибендә 15 минут эчендә;

баш тарту турындагы хатны почта аша җибәрү - әлеге Регламентның 3.5.3 пунктында каралган процедура тәмамланган вакыттан бер көн эчендә;

Процедуралар нәтиҗәсе: бирелгән акт яки муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу турында хат.

3.6.3 Шартнамә төзү һәм гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү

3.6.1. Палата белгече:

җир кишәрлеген милеккә яки арендага бирү шартнамәсе проектын әзерли (алга таба – шартнамә);

билгеләнгән тәртиптә шартнамә проектын килештерә һәм имзалый;

Палата рәисе имза салган шартнамәне теркәү журналында терки;

гариза бирүчегә, имза куйдырып, шартнамәне бирә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза теркәлгәннән соң ике көн эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә бирелгән шартнамә

3.6.2. Гариза бирүче акчаны (шартнамәдә күрсәтелгән сумманы) шартнамәдә күрсәтелгән исәп-хисап счетына күчерә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар килешү теркәлгәннән соң 10 көн эчендә башкарыла

Процедураларның нәтиҗәсе: күчерелгән акча.

3.6.3. Палата белгече, акча күчерү турында мәгълүмат алгач, өч нөсхәдә җир кишәрлеген кабул итү-тапшыру акты төзи. Гариза бирүчегә җир кишәрлеген кабул итү-тапшыру актының 3 нөсхәсен имза салу өчен бирә. Актка гариза бирүче имза салганнан соң, гариза бирүчегә 3 нөсхә җир кишәрлеген сату-алу шартнамәсен, 3 нөсхә җир кишәрлеген кабул итү-тапшыру актын бирә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза бирүче килгән көнне чират тәртибендә 15 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән шартнамә һәм кабул итү-тапшыру акты.

3.7. Муниципаль хезмәтне күпфункцияле үзәк аша күрсәтү.

3.7.1. Гариза бирүче муниципаль хезмәт алу өчен күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урынына мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

3.7.2. Муниципаль хезмәтне күпфункцияле үзәк аша күрсәтү күпфункцияле үзәкнең билгеләнгән тәртиптә расланган хезмәт регламенты нигезендә башкарыла.

Күпфункцияле үзәктән муниципаль хезмәт алу өчен документлар кергәндә процедуралар әлеге Регламентның 3.3 – 3.5 нче пунктлары нигезендә башкарыла. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе күпфункцияле үзәккә җибәрелә.

3.8. Техник хаталарны төзәтү.

3.8.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документта техник хаталар барлыгы ачыкланган очракта, гариза бирүче Палатага түбәндәге документларны тапшыра:

- техник хатаны төзәтү турында гариза (3 номерлы кушымта);

гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе буларак тапшырылган, техник хатасы булган документ;

техник хаталар булуны дәлилли торган, юридик көчкә ия документлар.

Техник хатаны төзәтү турында гариза муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән белешмәләрдә мөрәҗәгать итүче (аның вәкиле) шәхсән, яисә почта аша (шул исәптән электрон почта аша), яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы яисә КФҮ аша бирелә.

3.8.2. Документларны кабул итү өчен җаваплы белгеч техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кабул итә, аны беркетелгән документлар белән бергә терки һәм Палатага тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза теркәлгәннән соң бер көн эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, карап тикшерү өчен Палатаның җаваплы белгеченә җибәрелгән гариза.

3.8.3. Палата белгече документларны карап тикшерә һәм, муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булып торган документка төзәтүләр кертү максатыннан, әлеге регламентның 3.5 пункты белән билгеләнгән процедураларны гамәлгә ашыра һәм, гариза бирүчедән (вәкаләтле вәкилдән) техник хата булган документның төп нөсхәсен алып, төзәтелгән документны, имза куйдырып, гариза бирүчегә (вәкаләтле вәкилгә) шәхсән тапшыра яисә гариза бирүчегә почта (электрон почта) аша, техник хата булган документның төп нөсхәсен Палатага тапшырган очракта,

төзәтелгән документны алырга мөмкин булуы турында белдерү хаты юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура техник хата ачыкланганнан соң яки җибәрелгән хата турында теләсә кайсы кызыксынган заттан гариза алынганнан соң өч көн эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән (җибәрелгән) документ.

## 4.Муниципаль хезмәт күрсәтүне тикшерү тәртибе һәм формалары

4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу очракларын ачыклауны һәм бетерүне, муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешен тикшерүне, җирле үзидарә органындагы вазифаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата карарлар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формаларына түбәндәгеләр керә:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү буенча документ проектларын тикшерү һәм килештерү. Тикшерү нәтиҗәсе булып проектларны имзалау тора;

2) эш башкаруны алып бару буенча билгеләнгән тәртиптә тикшерүләр уздыру;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлеше буенча билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерүләр үткәрү.

Контроль тикшерүләр планлы (җирле үзидарә органының ярты еллык яки еллык эш планнары нигезендә башкарылырга) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр барышында муниципаль хезмәт күрсәтү белән бәйле барлык мәсьәләләр (комплекслы тикшерүләр) яки гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате карап тикшерелергә мөмкин.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә һәм карарлар кабул иткәндә гамәлләр кылуны контрольдә тоту максатыннан Палата рәисенә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләр тапшырыла.

4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеген саклауны агымдагы контрольдә тоту муниципаль хезмәт күрсәтү эшен оештыру өчен җаваплы Палата рәисе, шулай ук Палата белгече тарафыннан башкарыла.

4.3. Агымдагы контрольне гамәлгә ашыручы вазифаи затлар исемлеге җирле үзидарә органнарының структур бүлекчәләре турындагы нигезләмәләр һәм вазифаи регламентлар белән билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча гариза бирүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланса, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Җирле үзидарә органы җитәкчесе гариза бирүчеләрнең мөрәҗәгатьләрен вакытында карап тикшермәгән өчен җаваплы.

Җирле үзидарә органының структур бүлекчәсе җитәкчесе (җитәкче урынбасары) әлеге Регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрне вакытында һәм (яки) тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплы.

Вазифаи затлар һәм башка муниципаль хезмәткәрләр муниципаль хезмәт күрсәтү барышында кабул ителә торган карарлар һәм башкарыла (башкарылмый) торган гамәлләр өчен законда билгеләнгән тәртиптә җавап тота.

4.5. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүне контрольдә тоту муниципаль хезмәт күрсәткәндә Палата эшчәнлегенең ачыклыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль, дөрес мәгълүмат алу һәм муниципаль хезмәт күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карап тикшерү мөмкинлеге ярдәмендә гамәлгә ашырыла.

## 5.Муниципаль хезмәт күрсәтә торган органнарның, шулай ук алардагы вазифаи затларның, муниципаль хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе

5.1. Муниципаль хезмәттән файдаланучылар муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы Палата хезмәткәрләренең гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата Палата җитәкчесенә яисә муниципаль берәмлек башлыгына судка кадәр шикаять бирү хокукына ия.

Гариза бирүче шулай ук түбәндәге очракларда шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гаризасын теркәү вакытын бозу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү вакытын бозу;

3) мөрәҗәгать итүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Мөслим муниципаль районы норматив хокукый актларында каралмаган документларны яки мәгълүматны яисә гамәлләрне гамәлгә ашыруны таләп итү;

4) мөрәҗәгать итүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Мөслим муниципаль районы норматив хокукый актларында каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда кире кагу өчен нигезләр каралмаган булса, муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу.

6) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Мөслим муниципаль районы норматив хокукый актларында каралмаган түләүне муниципаль хезмәт күрсәткәндә таләп итү;

7) Палатаның, Палатаның вазифаи затының муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы хаталарны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуы яки мондый төзәтмәләрнең билгеләнгән вакытын бозуы.

8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү вакытын яки тәртибен бозу;

9) муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору нигезләре федераль законнар һәм Россия Федерациясенең алар нигезендә кабул ителгән башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган булса, әлеге хезмәт күрсәтүне туктатып тору.

10) 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешнең 4 пункты белән каралган очраклардан тыш, муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүне яки муниципаль хезмәт күрсәтүне беренче тапкыр кире какканда булмавы һәм (яки) дөрес түгеллеге күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп итү.

5.2. Муниципаль хезмәт күрсәтә торган орган, муниципаль хезмәт күрсәтә торган органда эшләүче вазифаи зат, муниципаль хезмәткәр, муниципаль хезмәт күрсәтә торган орган җитәкчесе тарафыннан кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауларына) шикаять язма формада кәгазьдә яки электрон формада бирелә.

Шикаять Мөслим муниципаль районының рәсми сайты булган "Интернет" челтәрен кулланып, почта аша, КФҮ аша җибәрелә ала (http://muslumovo.tatarstan.ru/), Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы (http://uslugi.tatar.ru/), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталы (http://www.gosuslugi.ru/), шулай ук гариза бирүченең шәхси кабул итүендә кабул ителергә мөмкин.http://muslumovo.tatarstan.ru/http://uslugi.tatar.ru/

5.3.Муниципаль хезмәт күрсәтә торган органга яки югары органга (булган очракта) кергән шикаять – аны теркәгән көннән соң унбиш эш көне эчендә, ә муниципаль хезмәт күрсәтә торган органның гариза бирүчедән документларны кабул итүдән яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгән очракта яисә мондый төр төзәтүләр кертүнең билгеләнгән вакытын бозуга карата шикаять белдерелсә, аны теркәгән көннән соң биш эш көне эчендә карап тикшерелергә тиеш.

5.4. Шикаять үз эченә түбәндәге мәгълүматны алырга тиеш:

1) хезмәт күрсәтүче органның, хезмәт күрсәтүче органның вазифаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең исеме, аларның карарлары һәм гамәлләре (гамәлсезлеге) шикаять ителә;

2) гариза бирүче физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәү урыны турында мәгълүматлар яки гариза бирүче юридик затның исеме, урнашу урыны турында мәгълүматлар, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиешле электрон почта адресы (булган очракта) һәм почта адресы;

3) муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәрнең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында белешмәләр;

4) муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органда эшләүче вазифаи затның яки муниципаль хезмәткәрнең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында мәгълүматлар;

5.5. Шикаятькә шикаятьтә язылган хәлләрне раслый торган документларның күчермәләре беркетелергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа беркетелә торган документлар исемлеге китерелә.

5.6. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән түләү алу каралмаган очракларда алынган акчаны гариза бирүчегә кире кайтару рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килә торган көннән соңга калмыйча, гариза бирүчегә язма рәвештә һәм гариза бирүче теләге буенча электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, гариза бирүчегә юллана торган җавапта, муниципаль хезмәт күрсәтү барышында ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатыннан, Палата тарафыннан башкарылучы гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу сорала һәм гариза бирүчегә, муниципаль хезмәттән файдалану максатында, алга таба башкарылырга тиешле гамәлләр турында мәгълүмат җиткерелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, гариза бирүчегә юллана торган җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга карата шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат китерелә.

5.9. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләтләре бирелгән вазифаи зат, хезмәткәр булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына юллый.

1 номерлы кушымта

Мөслим муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы
(муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы атамасы)
_________________________(физик затлар өчен – фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәү урыны, шәхесне таныклаучы документның реквизитлары, ИНН)
______________________________________
(юридик затлар өчен – атамасы, урнашу урыны, оештыру-хокукый формасы, Юридик затларның бердәм дәүләт реестрында дәүләт теркәве, Төп дәүләт теркәү номеры турында белешмәләр)
____________________________________________________________
(почта адресы, электрон почта адресы, элемтә өчен телефон номеры)

**Биналар, корылмалар, корылмалар урнашкан җир кишәрлеген милеккә (арендага) сатып алу турында гариза**

Мин, _________________________________________________________________,
(Гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Сездән Татарстан Республикасы _________________________ муниципаль районы _________________________________________________________ урнашкан гомуми мәйданы ____________ кв. м. булган __________ кадастр номерлы җир кишәрлеген милеккә (арендага) бирүегезне сорыйм
(җир кишәрлегенең һәм күчемсез милек объектларының урнашу урыны адресы күрсәтелә)

__________________________________________________________________________ хокукындагы
(даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану, гомерлеккә мирас итү яки файдалану)

______________ елдан ______________________________________________________________ нигезендә
(таныклый (билгеле) торган документның исеме, бирү датасы, номеры, кем тарафыннан бирелгән)

анда урнашкан (нар) _________________________________, хокукында ___
(күчемсез милек объекты күрсәтелә)

_____________ буенча ______________________________________________________________________,
(хокук төре күрсәтелә) (хокукны билгеләүче (таныклаучы) документның исеме, датасы, номеры, кем тарафыннан бирелгән)

өчен ______________________________, Россия Федерациясе Җир кодексы нигезендә.
(җир кишәрлегеннән файдаланунын рөхсәт ителгән төре)

Гаризага сканерланган түбәндәге документлар беркетелә:

1. Физик зат булып торучы гариза бирүченең (гариза бирүчеләрнең) шәхесен яисә физик зат яки юридик зат вәкиле шәхесен раслый торган документның күчермәсе;

2. Физик затның шәхси эшмәкәр буларак (шәхси эшмәкәрләр өчен) дәүләт теркәве турында таныклык күчермәсе, юридик затны (юридик затлар өчен) дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе яки җир кишәрлегенә хокуклар алу турында үтенеп гариза бирүче юридик зат яки шәхси эшмәкәр турында дәүләт реестрларыннан өземтә.

3. Әгәр гариза белән гариза бирүченең (гариза бирүчеләрнең)вәкиле мөрәҗәгать итсә, физик яисә юридик зат вәкиленең хокукларын (вәкаләтләрен) раслый торган документның күчермәсе.

4.* Сатып алына торган җир кишәрлегендә биналар, каралтылар, корылмалар булганда - сатып алына торган җир кишәрлегендә урнашкан бинага, каралтыга, корылмага хокуклар турында күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрыннан (алга таба - ЕГРН) өземтә яки:

4.1.* күрсәтелгән биналарга, каралтыларга, корылмаларга теркәлгән хокуклар турында соратып алына торган белешмәләрнең ЕГРНда булмавы турында хәбәрнамә;

4.2. әгәр Россия Федерациясе законнары нигезендә мондый бинага, каралтыга, корылмага хокук ЕГРНда теркәлүенә бәйсез рәвештә барлыкка килгән дип танысла икән, мондый бинага, каралтыга, корылмага хокукны раслый торган (билгели торган) документларның күчермәләре.

5.* Сатып алына торган җир кишәрлегенә хокуклар турында ЕГРНнан өземтә яки:

5.1.* күрсәтелгән җир кишәрлегенә теркәлгән хокуклар турында соратып алына торган белешмәләрнең ЕГРНда булмавы турында хәбәрнамә;

5.2. җир кишәрлегенә хокукны раслый торган (билгели торган) документларның күчермәләре, әгәр Россия Федерациясе законнары нигезендә әлеге җир кишәрлегенә хокук ЕГРНда теркәлүенә бәйсез рәвештә барлыкка килгән дип таныла икән.

6.* Күчемсез милек объектының төп характеристикалары һәм теркәлгән хокуклары турында ЕГРНнан өземтә, әгәр бу җир кишәрлегенә хокук алу турында гариза аңа хокукларны яңадан рәсмиләштерү максатында бирелгән булса.

7. Җир кишәрлеген, шул исәптән махсус шартларда, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез вакытлыча файдалануга, җир законнары белән билгеләнгән шартларда милеккә яки арендага алу хокукын бирә торган документ күчермәсе, әгәр бу хәл әлеге исемлекнең 1 - 6 пунктларында күрсәтелгән документлардан бирелмәсә, алу хокукын бирә торган шартларны раслый торган документ күчермәсе.

8. Гариза бирүченең (гариза бирүчеләрнең) кадастр (инвентарь) номерларын һәм адреслы ориентирларын күрсәтеп (гариза бирүчедә булган очракта) хокуклар алу турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегендә урнашкан барлык биналар, корылмалар, төзелмәләрнең исемлеген үз эченә алган хәбәре.

---

* документлар исемлегенең 2, 4, 4.1, 5, 5.1, 6 пунктларда күрсәтелгән җир кишәрлегенә хокуклар алу өчен кирәкле документлар җир кишәрлегенә хокуклар алу турында гариза бирүчедән таләп ителәалмый, шул ук вакытта гариза бирүче аларны җир кишәрлегенә хокуклар алу турында гариза белән бергә тапшырырга хокуклы.

Сораткада, сканерланган документларның төп нөсхәләрен тапшыруны үз өстемә алам.

| | | |
|---|---|---|
| ________________ | ____________ | ____________________________________________ |
| (дата) | (имза) | Фамилиясе, исеме, атасының исеме |

2 номерлы кушымта

**Җир кишәрлегенә хокуклар сатып алу турындагы мәсьәләне карау өчен кирәкле документлар исемлеге**

1. Физик зат булып торучы гариза бирүченең (гариза бирүчеләрнең) шәхесен яисә физик зат яки юридик зат вәкиле шәхесен раслый торган документның күчермәсе;

2. Физик затның шәхси эшмәкәр буларак (шәхси эшмәкәрләр өчен) дәүләт теркәве турында таныклык күчермәсе, юридик затны (юридик затлар өчен) дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе яки җир кишәрлегенә хокуклар алу турында үтенеп гариза бирүче юридик зат яки шәхси эшмәкәр турында дәүләт реестрларыннан өземтә.

3. Әгәр гариза белән гариза бирүченең (гариза бирүчеләрнең)вәкиле мөрәҗәгать итсә, физик яисә юридик зат вәкиленең хокукларын (вәкаләтләрен) раслый торган документның күчермәсе.

4.* Сатып алына торган җир кишәрлегендә биналар, каралтылар, корылмалар булганда - сатып алына торган җир кишәрлегендә урнашкан бинага, каралтыга, корылмага хокуклар турында күчемсез милекнең Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан (алга таба - ЕГРН) өземтә яки:

4.1.* күрсәтелгән биналарга, каралтыларга, корылмаларга теркәлгән хокуклар турында соратып алына торган белешмәләрнең ЕГРНда булмавы турында хәбәрнамә;

4.2. әгәр Россия Федерациясе законнары нигезендә мондый бинага, каралтыга, корылмага хокук ЕГРНда теркәлүенә бәйсез рәвештә барлыкка килгән дип таныла икән, мондый бинага, каралтыга, корылмага хокукны раслый торган (билгели торган) документларның күчермәләре.

5.* Сатып алына торган җир кишәрлегенә хокуклар турында ЕГРНнан өземтә яки:

5.1.* күрсәтелгән җир кишәрлегенә теркәлгән хокуклар турында соратып алына торган белешмәләрнең ЕГРНда булмавы турында хәбәрнамә;

5.2. җир кишәрлегенә хокукны раслый торган (билгели торган) документларның күчермәләре, әгәр Россия Федерациясе законнары нигезендә әлеге җир кишәрлегенә хокук ЕГРНда теркәлүенә бәйсез рәвештә барлыкка килгән дип таныла икән.

6.* Күчемсез милек объектының төп характеристикалары һәм теркәлгән хокуклары турында ЕГРНнан өземтә, әгәр бу җир кишәрлегенә хокук алу турында гариза аңа хокукларны яңадан рәсмиләштерү максатында бирелгән булса.

7. Җир кишәрлеген, шул исәптән махсус шартларда, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез вакытлыча файдалануга, җир законнары белән билгеләнгән шартларда милеккә яки арендага алу хокукын бирә торган документ күчермәсе, әгәр бу хәл әлеге исемлекнең 1 - 6 пунктларында күрсәтелгән

документлардан бирелмәсә, алу хокукын бирә торган шартларны раслый торган документ күчермәсе.

8. Гариза бирүченең (гариза бирүчеләрнең) кадастр (инвентарь) номерларын һәм адреслы ориентирларын күрсәтеп (гариза бирүчедә булган очракта) хокуклар алу турында гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегендә урнашкан барлык биналар, корылмалар, төзелмәләрнең исемлеген үз эченә алган хәбәре.

---

* документлар исемлегенең 2, 4, 4.1, 5, 5.1, 6 пунктларда күрсәтелгән җир кишәрлегенә хокуклар алу өчен кирәкле документлар җир кишәрлегенә хокуклар алу турында гариза бирүчедән таләп ителә алмый, шул ук вакытта гариза бирүче аларны җир кишәрлегенә хокуклар алу турында гариза белән бергә тапшырырга хокуклы.

3 номерлы кушымта

_______________ муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре Палатасы рәисенә
___________________________

**Техник хатаны төзәтү турында гариза**

**Муниципаль хезмәт күрсәткәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм________________________________________________________________**

(хезмәт атамасы)

Язылган:
________________________________________________________________________________
_____________________________________________________

Дөрес мәгълүматлар:____________________________________________________
______________________________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүегезне һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып торган документка тиешле үзгәрешләр кертүегезне сорыйм.

Түбәндәге документларны беркетәм:

1.

2.

3.

Техник хатаны төзәтү турында гаризаны кире кагу турында карар кабул ителгән очракта, мондый карарны:

электрон документ җибәрү аша ________________________e-mail адресына;

- расланган күчермә рәвешендә кәгазь чыганакта почта аша _________________________________________________________________ адресына җибәрүегезне сорыйм.

Муниципаль хезмәт күрсәтү максатыннан, алар нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтә торган орган тарафыннан карарлар кабул ителүне исәпкә алып, шул исәптән автоматлаштырылган тәртиптә, шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә (җыю, системага салу, туплау, саклау, тәгаенләү (яңарту, үзгәртү), файдалану, тарату (шул исәптән тапшыру), шәхессезләндерү, ябу, шәхси мәгълүматларны юк итү, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү кысаларында шәхси мәгълүматларны эшкәртү өчен кирәкле булган башка гамәлләр) үземнең ризалыгымны, шулай ук минем тарафтан вәкаләт бирелгән затның ризалыгын раслыйм.

Әлеге гариза белән аңа кертелгән, шәхесемә һәм мин вәкиле булып торган затка

кагылышлы, шулай ук минем тарафтан түбәндә кертелгән мәгълүматларның дөрес булуын раслыйм. Гаризага теркәлгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән таләпләргә җавап бирә, гаризаны тапшыру вакытына әлеге документлар гамәлдә һәм алардагы мәгълүматлар дөрес.

Миңа күрсәтелгән муниципаль хезмәтнең сыйфатын бәяләү буенча ______________________ телефоны аша сораштыруда катнашырга ризалыгымны бирәм.

| | | |
|---|---|---|
| ______________ | __________________ | ( _________________) |
| (дата) | (имза) | (фамилиясе,исеме, атасының исеме) |

Кушымта
(белешмә)

**Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы һәм аның үтәлешен контрольдә тотучы вазифаи затларның реквизитлары**

**Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты:**

| Вазифасы | Телефон номеры | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | **2-45-68** | Muslum@tatar.ru |
| Палата Рәисе | **2-47-33**<br>**2-54-50** | Pizo.Muslyumovo@tatar.ru |

**Мөслим муниципаль районы Советы**

| Вазифасы | Телефон номеры | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Муниципаль район Башлыгы | **2-45-00**<br>**2-42-66** | Glavy.Priemnaya.musl@tatar.ru |